ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02 июнь 2023 ел № 4674

Башкарма комитетның 2019 елның 5 декабрендәге 6326 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең махсуслаштырылган торак фонды тулай торакларында торак урыннары бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2019 елның 5 декабрендәге 6326 номерлы карары (Башкарма комитетның 2020 елның 14 апрелендәге 1825 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәренең махсуслаштырылган торак фонды тулай торакларында торак урыннары бирү тәртибенә, 8 пунктта 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«2) яшәү урыны буенча теркәлү исәбе турында мәгълүматлар (гариза бирүче үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы);».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары А.С. Ганиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов